Централизованная религиозная организация
Духовное управление мусульман
Российской Федерации

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ,
РОССИЯ МӨФТИЛӘР ШУРАСЫ РӘИСЕ**

**МӨФТИ ШӘЕХ
РАВИЛ ГАЙНЕТДИННЕҢ**

**ГЫЙД ӘЛ-ӘДХА — КОРБАН ГАЕТЕ
МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН**

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

**Мәскәү**
1443 һиҗри елның
10 зөлхиҗҗә көне
9 июль 2022 ел

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

**БИСМИЛЛӘӘҺИР-РАХМӘӘНИР-РАХИИИМ — Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһ исеме белән!**

الحمد لله رب العالمين

والصلاة والسلام على نبينا محمد

وعلى آله وصحبه أجمعين

Әлхәмдү лилләһи Раббил гаәләмиин. Вәс-саләәтү вәс-сәләәмү галәә Расүүлинәә Мухаммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Җирдәге вә күк йөзендәге бар мәхлукат тарафыннан макталучы галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһу Сөбханәһу вә Тәгаләгә мактау булсын! Пәйгамбәребез Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

السلام عليكم ورحمة الله وبركاته

Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ —

Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

**Кадерле дин кардәшләрем!**

Без — Россия Федерациясе мөселманнары, бар дөнья мөселманнары кебек үк Исламдагы ике зур бәйрәмнең берсен, Хаҗ гамәлләре төгәлләнүне белдерүче Гыйд әл-Әдха — Корбан гаетен бәйрәм итәбез. Пандемия аркасында Мәккә-и-Мөкәррәмә шәһәренә керүгә чикләүләр булып, ике еллык мәҗбүри тәнәфестән соң, ниһаять быел җир шарының төрле почмакларыннан, шул исәптән Россиядән дә хаҗилар Хаҗ гамәлләрен үти ала.

Хаҗилар ихлас хисләр, күз яшьләре, Бер һәм Бердәнбер Аллаһка бирелгәнлек илә, Аллаһка гыйбадәт кылыр өчен җир йөзендә төзелгән иң беренче урынга юнәлеп, Бер, Бердәнбер, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы Сөбханәһу вә Тәгаләдән башка яклаучы булмас Мәхшәр мәйданына җыелган сыман Раббылары каршына килә һәм Хаҗның билгесе булган тәлбия сүзләрен кабатлый:

لَبَّيْكَ اللَّهُمَّ لَبَّيْكَ، لَبَّيْكَ لاَ شَرِيكَ لَكَ لَبَّيْكَ، إِنَّ الْحَمْدَ، وَالنِّعْمَةَ، لَكَ وَالْمُلْكَ، لاَ شَرِيكَ لَكَ

**Ләббәйкәллаһүммә ләббәйк, ләббәйкә ләә шәриикә ләкә, ләббәйк! Иннәл-хәмдә вән-нигъмәтә ләкә вәл-мүлк, ләә шәриикә ләк! «Йә Аллаһ, менә мин Синең каршыңда! Менә мин синең каршыңда! Сиңа тиң бернинди зат юк! Барча мактау Сиңа гына! Бар нигъмәт һәм хөкем Синдә генә! Сиңа тиң бернинди зат юк!»**

Планетаның бар континентларыннан төрле кыйтга һәм миллät мөселманнары Изге Мәккәкә Хаҗ кылып, Аллаһның Расүле ﷺ юлын кабатлый һәм хаҗиларның күңеле Раббыларына, Аның мәхлүкатына, бернинди аерма ясамыйча, ярату хисләре белән тулган.

Пәйгамбәребез ﷺ Хаҗ турында:

الحج عرفة

**Хаҗ — Гарәфәдә тору,** — дигән.

Бу көн нинди гүзәл! Яум Гарәфә, Гарәфә көне! Миллионнан артык мөселман Гарәфә үзәнлегендә тору өчен генә яшәгән урыннарын, Ватаннарын, эш-мәшәкатьләрен, мал-мөлкәтен калдырып, монда килгән! Хакълыкта, Гарәфә үзәнлегендә тору — Хаҗның бар мәгънәсе, аның асылы.

Йә, Аллаһ, хаҗиларыбызның догаларын кабул ит, аларга көч, догаларында ихласлык бир һәм Ватаннарына имин рәвештә кайтар! Йә, Раббым, безгә әлеге якты бәйрәмне әле тагын күп тапкырлар күрергә насыйп ит!

Хаҗның иң югары ноктасы — корбан чалу, ул барыбыз өчен дә бөек бер дәрес һәм нәсыйхәт. Мәгълүм булганча, корбан чалу Ибраһим галәйһиссәлам вә аның улы Исмәгыйл галәйһиссәлам заманнарыннан ук килә торган йола.

Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә, Ибраһим галәйһиссәламнең төшен тасвирлый. Аңа сынау рәвешендә, яраткан улын корбанга китерергә әмер ителә. Авырлыкларга карамастан, ата белән ул Аллаһы Тәгаләнең боерыгыннан тайпылмый.

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَى فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ مَاذَا تَرَى قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ

**«Ул аның белән йөрерлек яшькә җиткәч, аңа: «И минем улым, мин бит төшемдә сине бугазлыйм итеп күрдем. Кара инде нинди фикердә син», — диде. Улы аңа: «И минем атам, үзең кушылган нәрсәне эшлә. Мине син, Аллаһ теләсә, түзүчеләрдән итеп табарсың», — диде».** *(«Әс-саффат» сүрәсе, 102 а.)*

Әмма Аллаһы Тәгаләгә корбаннар кирәкми, бу Ибраһим галәйһиссәлам өчен сынау була. Изге Коръәндә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَكِن يَنَالُهُ التَّقْوَى مِنكُمْ

**«Ул корбаннарның ите дә, каны да Аллаһка барып җитмәс, әмма сезнең Аллаһка тыпшырылуыгыз, ихлас эшегез барып җитәр», — диелгән.** *(«Әл-Хаҗ» сүрәсе, 37 а.)*

Бүген без сынаулар аша узабыз һәм шушы вакытта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлламнең мәңгелек кулланмасын, аның хушлашу нәсыйхәтен, вәгазен һәм хушлашу Хаҗын онытмаска тиеш. Яктылык һәм аң-белем таратыгыз, тиран һәм җәберләүче түгел, ә кешелек өчен остаз булыгыз! Игелек һәм иминлек орлыкларын чәчегез, яхшылыкка чакырыгыз һәм башкаларга үрнәк булыгыз!

وَعَدَ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ لَيَسْتَخْلِفَنَّهُم فِي الْأَرْضِ كَمَا اسْتَخْلَفَ الَّذِينَ مِن قَبْلِهِمْ وَلَيُمَكِّنَنَّ لَهُمْ دِينَهُمُ الَّذِي ارْتَضَى لَهُمْ وَلَيُبَدِّلَنَّهُم مِّن بَعْدِ خَوْفِهِمْ أَمْنًا يَعْبُدُونَنِي لَا يُشْرِكُونَ بِي شَيْئًا وَمَن كَفَرَ بَعْدَ ذَلِكَ فَأُوْلَئِكَ هُمُ الْفَاسِقُونَ

**«Сездән иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләрне Аллаһ элеккеге кешеләрне ничек урынбасарлар иткән, шуның кебек Ул аларны да урынбасарлар итәчәк. Шулай ук алар өчен Үзе риза булып кылган диннәрен, әлбәттә, өстен кылачак һәм аларның моңа кадәр булган куркынычларын тынычлык белән алыштырачак. «Алар һичнәрсәне тиңдәш итми, Миңа гыйбадәт кылачаклар», — дип вәгъдә итте. Кем дә кем шуннан соң карышса, әнә шулар инде фасикъләр».** *(«Ән-нур» сүрәсе, 55 а.)*

Бәйрәм намазында йөзләгән һәм меңләгән дин кардәшләр белән иңгә-иң торып, туганнар һәм күршеләрне бәйрәм нигъмәләре белән сыйлап, кайсы милләттән һәм нинди дин тотуына карамастан, ярлыларга һәм мохтаҗларга корбанлык итләрен өләшеп, үзебездә кардәшлек мәхәббәтен ныгытабыз һәм шул рәвешле иманыбызны куәтлибез. Чөнки Аллаһның соңгы Пәйгамбәре салләллаһу галәйһи вә сәллам:

وَالَّذِي نفسي بيدِهِ لا تدخلوا الجَنَّةَ حتَّى تؤمنوا ولا تؤمنوا حتَّى تحابُّوا

*«Җаным Аллаһ хөкемендә булган Аллаһ белән ант итәм, иман китермичә җәннәткә кермәссез. Әбер-берегезне яратмыйча, иман китерә алмассыз», — дигән. (Сәхих, Мөслим)*

Бөек бәйрәм көннәрендә без Аллаһы Тәгаләдән гомумкешелек туганлыгын ныгытуын, һәртөрле фетнә һәм низаглардан саклавын, йөрәкләребезне үзара мәхәббәт һәм мәрхәмәт хисләре белән тулыландыруын, бар дөньяга тынычлык һәм иминлек иңдерүен сорыйбыз!

Догалар кабул була торган, гөнаһлар кичерелә торган бу көннәрдә тагын бер кат Раббыбызга мөрәҗәгать итик — йә, Аллаһ, корбаннарыбызны кабул ит һәм бетмәс-төкәнмәс әҗерен бир, кардәшләребезнең Хаҗын кабул ит, догаларыбызны һәм игелекле гамәлләребезне кабул ит! Йөрәкләребезне тәкъвалыкта һәм иманда куәтлә!

Аллаһы Раббыбыздан үзебезнең Ватаныбызга тынычлык һәм тотрыклылык, гаиләләребезгә сәламәтлек һәм уңышлар, авыруларга дәва һәм шифа, ярлыларга һәм мохтаҗларга ризык һәм бәрәкәтен сорыйбыз! Гыйд әл-Әдха мөбарәк булсын!

والسلام عليكم ورحمة الله وبركاته

Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ!

**Мөфти шәех Равил Гайнетдин,**
Россия Федерациясе мөселманнары
Диния нәзарәте рәисе,
Россия мөфтиләр шурасы рәисе